**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 26 август | № 593

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел, 14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмәнең 5.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасарлары, аның территориаль органнары һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясенә беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

төп нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасарлары, аның территориаль органнары һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый;

Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе өчен билгеләнгән төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә үз карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе структурасында:

«хокук бүлеге» сүзләрен «административ һәм суд практикасы бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

«кадрлар бүлеге» сүзләрен «кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы тору бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков